КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 28 февраль г.Казань № 127

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 13 июнь, 372 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 13 июнь, 372 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибен һәм Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр компенсация түләүләре бирү тәртибен раслау турында»;

преамбулада «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 15 апрель, 294 нче карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 26 декабрь, 1640 нчы карары» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

«Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибе;

Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр компенсация түләүләре бирү тәртибе.»;

әлеге карар белән расланган «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү тәртибендә:

1 пунктта «2017 елда» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасын өстәргә:

«е) авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күчеп килгән) 50 яшькәчә медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру.»;

6 пунктта «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 елларның план чорына» сүзләрен «тиешле финанс елына һәм план чорына» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«әлеге Тәртипнең 4 пунктының «е» пунктчасында:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүне үрнәк формасын раслау хакында» 2016 ел, 22 декабрь, 17-148 нче боерыгы белән расланган форма буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосындагы, бюджет һәм автоном учреждениеләр булган Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмалары белән (алга таба – медицина оешмалары) Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешү төзи;

медицина оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирә;

биләп торганда бер тапкыр компенсация түләүләре гамәлгә ашырыла торган медицина оешмалары һәм аларның структур бүлекчәләрендә медицина хезмәткәрләре вакантлы вазыйфалары реестрын (вазыйфаларның программа реестры) алып бара;

бер тапкыр компенсация түләүләре гамәлгә ашырыла торган айга кадәр айның 13енә кадәр Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы билгеләгән форма буенча Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына заявка тапшыра;

бер тапкыр компенсация түләүләре гамәлгә ашырыла торган айның 5сенә кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы белән расланган форма буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына заявка тапшыра;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы раслаган форма буенча бер тапкыр компенсация түләү турында медицина хезмәткәрләре белән шартнамәләр төзи.»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү турында килешү белән билгеләнә торган вакытларда һәм формада субсидияләрдән файдалану һәм субсидияләрдән файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.»;

әлеге карарга Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр компенсация түләүләре бирү тәртибен өстәргә (теркәлгән).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Бер тапкыр түләнә торган компенсация түләүләре турында» 2012 ел, 23 гыйнвар, 35 нче;

«Бер тапкыр түләнә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга һәм медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр түләнә торган компенсация түләүләрен бирүгә чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 13 февраль, 111/1 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бер тапкыр түләнә торган компенсация түләүләре турында» 2012 ел, 23 гыйнвар, 35 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2012 ел, 22 июнь, 542 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 4 июль, 477 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 26 апрель, 270 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 ел, 30 апрель, 301 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 25 февраль, 115 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бер тапкыр түләнә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга һәм медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр түләнә торган компенсация түләүләрен бирүгә чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 13 февраль, 111/1 нче карары белән расланган Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр түләнә торган компенсация түләүләрен бирүгә чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2016 ел, 26 май, 358 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 ел, 28 февраль, 119 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бер тапкыр түләнә торган компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга һәм медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр түләнә торган компенсация түләүләрен бирүгә чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 13 февраль, 111/1 нче карары белән расланган Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр түләнә торган компенсация

түләүләрен бирүгә чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү тәртибенә үзгәреш кертү хакында» 2017 ел, 28 июнь, 446 нчы.

3. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 13 июнь, 372 нче карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 28 февраль, 127 нче карары редакциясендә

Медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга)
бер тапкыр компенсация түләүләре бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) бер тапкыр компенсация түләүләре бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

2. 50 яшькәчә Россия Федерациясе гражданы булган, максатчан укыту шартнамәсе буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмаган, авыл торак пунктларына, яисә эшчеләр поселокларына, яисә шәһәр тибындагы поселокларга, яисә 50 мең кешегә кадәр халкы булган шәһәрләргә эшкә килгән (күчеп килгән) һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 350 статьясы нигезендә билгеләнгән эш вакыты озынлыгы белән тулы эш көне шартларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган вазыйфаларның программа реестрына кертелгән вазыйфада хезмәт функцияләрен үтәү белән, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствосындагы Татарстан Республикасы дәүләт медицина оешмасы белән хезмәт шартнамәсе төзегән медицина хезмәткәрләренә (табибларга, фельдшерларга) табиблар өчен 1 млн. сум һәм фельдшерлар өчен 500 мең сум күләмендә бер тапкыр компенсация түләүләре (алга таба – бер тапкыр компенсация түләүләре) билгеләнә.

3. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән табибка бирелә торган бер тапкыр компенсация түләве күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{вр} = 1 \times L,$$

монда:

1 – табибка бирелә торган 1 млн. сумга тигез бер тапкыр компенсация түләве күләме;

L – федераль бюджеттан Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәсен финанслашуның Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында төзелә торган «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын тормышка ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү турында килешү белән (алга таба – килешү) билгеләнә торган чик дәрәҗәсе.

федераль бюджеттан субсидия исәбеннән табибка бирелә торган бер тапкыр компенсация түләве күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{вф} = 1 - V_{вр},$$

монда:

1 – табибка бирелә торган 1 млн. сумга тигез бер тапкыр компенсация түләве күләме;

$V_{вр}$ – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән табибка бирелә торган бер тапкыр компенсация түләве күләме.

4. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән фельдшерга бирелә торган бер тапкыр компенсация түләве күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{фр} = 0{,}5 \times L,$$

монда:

0,5 – фельдшерга бирелә торган 0,5 млн. сумга тигез бер тапкыр компенсация түләве күләме;

L – федераль бюджеттан Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәсен финанслашуның килешү белән билгеләнә торган чик дәрәҗәсе.

Федераль бюджеттан субсидия исәбеннән фельдшерга бирелә торган бер тапкыр компенсация түләве күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_{фф} = 0{,}5 - V_{фр},$$

монда:

0,5 – фельдшерга бирелә торган 0,5 млн. сумга тигез бер тапкыр компенсация түләве күләме;

$V_{фр}$ – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән фельдшерга бирелә торган бер тапкыр компенсация түләве күләме.

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр компенсация түләүләре бирү буенча һәм медицина хезмәткәрләре белән бер тапкыр компенсация түләүләре бирү турында шартнамәләр (алга таба – шартнамә) төзү буенча вәкаләтле орган булып тора.

6. Медицина оешмалары Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына медицина хезмәткәренә бер тапкыр компенсация түләве бирү турында шартнамә төзү өчен документлар һәм заявка җибәрә.

7. Бер тапкыр компенсация түләүләре Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан медицина хезмәткәре белән шартнамә төзегәннәргә бирелә, аның буенча медицина хезмәткәре түбәндәге йөкләмәләрне кабул итә:

хезмәт функциясен тулы күләмдә үтәмәгән чорда шартнамәне озайту шартларында (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 106 һәм 107 статьяларында каралган ял вакытыннан тыш) хезмәт шартнамәсе нигезендә вазыйфада шартнамә төзегән көннән соң 5 ел эчендә хезмәт йөкләмәләрен үтәргә;

хезмәт шартнамәсе туктатылган көннән алып 30 эш көне эчендә биш ел вакыт үткәнче хезмәт шартнамәсе туктатылган көннән алып бер тапкыр компенсация

түләүнең эшләнмәгән чорга пропорциональ исәпләнгән өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кайтарырга (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешнең 8 пункты, 83 статьясындагы беренче өлешнең 5 – 7 пунктларында каралган нигезләр буенча хезмәт шартнамәсен туктату очракларыннан тыш), шулай ук башка вазыйфага күчкәндә яки өстәмә һөнәри программалар буенча укырга кергәндә;

хәрби хезмәткә чакырылу белән бәйле эштән киткән очракта хезмәт шартнамәсе туктатылган көннән алып 30 эш көне эчендә бер тапкыр компенсация түләүнең эшләнмәгән чорга пропорциональ исәпләнгән өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кайтарырга (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 83 статьясындагы беренче өлешнең 1 пункты нигезендә) яки функциональ йөкләмәләрен үтәмәгән чорга шартнамәнең гамәлдә булу вакытын озайтырга (медицина хезмәткәре сайлавы буенча).

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бер тапкыр компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өчен медицина оешмаларына субсидияләр рәвешендә акча күчерә.

9. Медицина оешмалары ике эш көне эчендә алынган бер тапкыр компенсация түләүләрен медицина хезмәткәре кредит оешмасында ачкан счетка күчерәләр.

10. Бер тапкыр компенсация түләүләрен күчерү вакыты шартнамә төзелгән көннән соң 30 эш көненнән артмаска тиеш.

11. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы түбәндәге очракларда субсидияләр күләмен киметүне һәм (яки) бирелгән субсидияләрне өлешчә (тулысынча) кайтаруны тәэмин итә:

күрсәтелгән акчаларга ихтыяҗ булмау (кимү);

медицина оешмалары дөрес булмаган бюджет заявкалары һәм хисап бирү;

медицина оешмалары акчаны максатка ярашсыз файдалану;

медицина оешмасы белән хезмәт шартнамәсе медицина хезмәткәре тарафыннан биш ел вакыт узганчы туктатылу (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы беренче өлешнең 8 пункты, 83 статьясындагы беренче өлешнең 5 – 7 пунктларында каралган нигезләр буенча хезмәт шартнамәсен туктату очракларыннан тыш), шулай ук башка вазыйфага күчкәндә яки өстәмә һөнәри программалар буенча укырга кергәндә, медицина хезмәткәре эшләмәгән чорга пропорциональ рәвештә хезмәт шартнамәсен туктату көненнән исәпләнгән бер тапкыр компенсация түләүләре өлешендә.

12. Әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән фактлар билгеле булган очракта субсидияләр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләбен алган көннән соң 15 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия алучылар субсидияләрне кире кайтару вакытын бозганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге пунктның беренче абзацында билгеләнгән вакыт узган көннән соң 30 көн эчендә әлеге акчаларны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына алу чараларын күрә.

13. Бюджет акчасын максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына йөкләргә.

___